КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 17 май г.Казань № 603

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Татарстан Республикасының Кайбыч муниципаль районында «Бушанча – Кече Урсак» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасының Кайбыч муниципаль районында «Бушанча – Кече Урсак» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы адресы буенча урнашкан, «Август-Кайбыч» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – алына торган җир кишәрлеге милекчесе) милкендә булган, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясендәге 928 969,24 кв.метр мәйданлы, 16:21:000000:130 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 2 399 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген (алга таба – алына торган җир кишәрлеге) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Алына торган җир кишәрлегендә урнашкан 16:21:000000:709 кадастр номерлы «Юл транспорты корылмасы. Хуҗа Хәсән авылына керү юлы», 16:21:000000:476 кадастр номерлы «Юл транспорты корылмасы. Татарстан

Республикасының Кайбыч муниципаль районында «Кошман – Бушанча – Олы Урсак» автомобиль юлын реконструкцияләү» күчемсез мөлкәт объектлары алынмаска тиеш дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлеге милекчесенә, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлеге милекчесенә җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләүне;

алына торган җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган җир кишәрлеге милекчесе тарафыннан имза куелган килешү законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъва бирүне.

4. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасының Кайбыч муниципаль районында «Бушанча – Кече Урсак» автомобиль юлын төзү» объекты өчен территорияне планировкалау проектын һәм межалау проектын раслау турында» 2022 елның 13 июлендәге 326 номерлы карары белән расланган территорияне планировкалау проекты һәм межалау проекты нигезендә 16:21:000000:130 кадастр номерлы җир кишәрлегенә һәм алына торган җир кишәрлегенә карата кадастр эшләрен үткәрүне тәэмин итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин